МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

Пушкин ур., 66/33нче йорт, Казан ш., 420015

Тел.: (843) 264-74-01, факс: (843) 292-07-26. mkrt@tatar.ru, mincult.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** г.Казань **БОЕРЫК**

**09.11.2017** **№ 993 од**

Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты, 1910, арх.Олешкевич К.С.” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясен раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законы, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында,

**БОЕРАМ:**

1. Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты, 1910, арх.Олешкевич К.С.” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга (1 нче кушымта).
2. Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты, 1910, арх.Олешкевич К.С.” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга (2 нче кушымта).
3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасының
мәдәният министрлыгы
09.11.2017 ел 993 од боерыгына
1 нче кушымта

Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты, 1910, арх.Олешкевич К.С.” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе ЧИКЛӘРЕ




Условные обозначения:

объект культурного наследия

территория объекта культурного наследия

Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты , 1910, арх.Олешкевич К.С.” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картографик тасвирламасы**

Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

**Төньяк-көнбатыш өлеш**: Мөштәри урамының җөп ягы буйлап, кызыл сызык буенча (5-1 борылыш нокталары);

**Төньяк-көнчыгыш өлеш**: Мөштәри урамыннан, бинаның кырый капиталь дивары буйлап (1-3 борылыш нокталары);

**Көньяк-көнчыгыш өлеш**: бинаның арткы дивары буйлап, Щапов урамы юнәлешендә (3-4 борылыш нокталары);

**Көньяк-көнбатыш өлеш**: Мөштәри урамынаа таба, бинаның кырый капиталь диварлаы буйлап (4-5 борылыш нокталары).

Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты, 1910, арх.Олешкевич К.С.” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең

**борылыш нокталары таблицасы**

| № точки | Координаты точки в МСК-16 | | Координаты поворотных точек во Всемирной геодезической системе координат (WGS-84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Широта, B | Долгота, L |
| 1 | 476131.99 | 1306475.00 | 55°47'32.96" | 49°08'05.69" |
| 2 | 476129.28 | 1306490.52 | 55°47'32.88" | 49°08'06.58" |
| 3 | 476125.18 | 1306514.04 | 55°47'32.74" | 49°08'07.93" |
| 4 | 476096.80 | 1306510.16 | 55°47'31.82" | 49°08'07.71" |
| 5 | 476101.17 | 1306470.67 | 55°47'31.97" | 49°08'05.44" |

Татарстан Республикасының
мәдәният министрлыгы
09.11.2017 ел 993 од боерыгына
2 нче кушымта

Казан шәһәре, Мөштәри урамы, 20-нче йорт адресы буенча урнашкан “И.Н.Киселев табыш йорты, 1910, арх.Олешкевич К.С.” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең файдалану режимы

төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә **рөхсәт ителә**:

мәдәни мирас объектының физик яктан саклануын тәэмин итүгә юнәлтелгән саклау эшләре үткәрү, шул исәптән, консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм заманча файдалануга яраклаштыру;

мәдәни мирас объектының бөтенлегенә зыян салмаган һәм мәдәни мирас объектын бүгенге шартларда кулланылуын тәэмин итү мөмкинлеге биргән хуҗалык эшчәнлеге алып бару;

мәдәни мирас объектының юкка чыккан өлешләрен һәм элементларын, тарихи аналоглары, булган сызымнары һәм үлчәмнәре җирлегендә элеккеге хәленә кайтару;

мәдәни мирас объектының бөтенлеген бозып торган вакытлы корылмаларны һәм объектларны сүтү;

әлеге эшләр мәдәни мирас объектына зыян салмаса (шул исәптән, динамик тәэсир), булган объектларның инженерлык инфраструктурасын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон кертү буенча тышкы челтәрләрне) капиталь ремонтлау;

мәдәни мирас объектын саклау, файдалану һәм популярлаштыру максатыннан территорияне тәртипкә китерү;

- мәйданчыкларга, якын килү һәм транспорт узу урыннарына традицион материаллар (таш, гранит һәм табигый булып күренә торган башка материаллар) түшәү;
- тарихи мохит элементлары характеристикаларына туры килгән аерым урнаштырылган яктырту җайланмаларыннан файдалану;
- агачларның кыйммәтле төрләрен саклау;
- булган капиталь төзелеш объектларын, шулай ук җир кишәрлекләрен (капиталь төзелеш объектлары сафка бастырмыйча Һәм вакытлы корылмалар урнаштырмыйча) Россия Федерациясенең икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 1 сентябрендә кабул ителгән 540-нчы номерлы боерыгы белән расланган “Җир кишәрлекләрен рәхсәт ителгән куллану төрләре классификаторы ” нигезендә файдалану:

- аз этажлы күп фатирлы торак төзелеше (код 2.1.1);
- урта этажлы торак төзелеше (код 2.5);
- торак төзелешенә хезмәт күрсәтү (код 2.7);

- иҗтимагый хезмәт күрсәтү (код 3.2);
- мәгариф һәм мәгърифәт (код 3.5);
- мәдәни үсеш (код 3.6.);
- иҗтимагый идарә итү (код 3.8);
- фәнни эшчәнлекне тәэмин итү (код 3.9);
- эшмәкәрлек (код 4.0);
- тарихи-мәдәни эшчәнлек (код 9.3);

Фасадта мәгълүмәти язулар һәм билгеләмәләр, мемориаль такталарны мәдәни мирас объектының беренче этажыннан югары итмичә урнаштыру;

Кануннар нигезендә, реклама характерында мәгълүмәте булмаган, дәүләт хакимияте органнарының, урындагы үзидарә органнарының, коммерциячел булмаган оешмаларның элмә такталарын һәм күрсәткечләрен урнаштыру, эшчәнлек профиле турында, оешманың фирма атамасын, аның урнашкан урынын (адресын) һәм эш режимын, шәхси эшмәкәрнең дәүләт теркәве һәм аны теркәгән органны кулланучыларга җиткерү өчен билгеләнгән элмә такталар кую. Декоратив-сәнгати рәсемнәрдән тыш, башка элмә такталарның биеклеге теге яки бу конструкцияне кую чикләрен регламентацияләнгән фриз, этаж тәрәзәләре арасы биеклегенең 2/3 өлешеннән зуррак булырга тиеш түгел. Аркасыман тәрәзәләр булганда этаж тәрәзәләре арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге ½ өлешкә кадәр азая. Мәгълүмәти конструкцияләрнең киңлеге теге яки бу конструкцияне кую чиген регламентицияләүче стена арасы киңлегенең 2/3 өлешеннән зур булмаска тиеш;

археологик белешмәләр булган очракта территориянең директив дәрәҗәсен түбәнәйтү, ишегалды территориясен вертикаль планлаштыру;

Югарыда аталган барлык эшләр вәкаләтле мәдәни мирас объектын саклау органы тарафыннан килештерелгән мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәләр һәм проект документлары нигезендә, вәкаләтле мәдәни мирас объектын саклау органы тарафыннан бирелгән мәдәни мирас объектын саклау эшләре үткәрергә язмача рөхсәт кәгазе нигезендә башкарыла.

Мәдәни мирас объектының территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

Капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен урнаштыру, шулай ук җир төзү эшләрен проектлау һәм уздыру, мәдәни мирас объектларын саклауга бәйле булмаган җир, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшләр башкару;

мәдәни мирас объекты фасадына һәм түбәсенә кондиционерлар, эре габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын урнаштыру;

инженерлык инфараструктурасы объектларын (суүткәргечнең тышкы челтәре, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) җир өстеннән үткәрү;

автомобильләргә ачык һәм ябык туктау урыны кую;

санитар кисүдән тыш, агачларның кыйммәтле төрләрен кисү.